

21 февральдә Мордовиянен А.С.Пушкин исемен йорткән Милли китапханәсендә Мәдәният, милли сәясәт, туризм һәм архив эшләр министрлыгы ярдәмендә Идел буе фин-угр халыклары мәдәнияты Үзәге (Поволжский центр культур финно-угорских народов) «Туган тел – халык кvнелендә!» дигән әдәби-музыкаль кичә vткәрде. Халыкара туган тел конендә мордва телләре буенча vткән регионара олимпиадасында катнашкан чит регион вәкилләре дә булды.

Халыкара туган тел коне телләрне һәм мәдәниятләрне яклау һәм саклау проб-лемасына донья җәмәгатьчелегенен игътибарын юнәлтv максатында 1999 елнын 17 ноябрендә ЮНЕСКО Генераль конференциясенен 30 сессиясендә гамәлгә куелган иде. Һәм бу бәйрәм жир шарынын ботен почмагында да билгеләп vтелә. Халыкара туган тел конен vткәрv Мордовиядә матур традициягә әйләнде.
“Хәзерге вакытта доньяда жиде меннән артык тел һәм диалект исәпләнелә. Ләкин, барлык терек-лек кебек vк, аралашу теле дә яшәvдән туктарга момкин. Сонгы вакытта аларнын саны кими бара һәм кvпчелегенә ботенләй юкка чыгу куркынычы яный. Бу – билгеле бер дәрәҗәдә коммуникацияләр vсешенә, глобальләшv басымына, халыкнын миграциясенә бәйле һәм ботен доньяны борчый торган мәсьәлә...”, - дип сvзен башлады Мордовия мәдәният, милли сәясәт һәм архив эшләре министры беренче урынбасары Александр Иванович Карьгин. Ул регионыбыз халкынын дус-тату яшәве, аларнын милли мәдәниятларын, телләрен саклау буенча башкарылган эшләр, унышлар турында сойләде һәм бу олкәдә алдынгы хезмәткәрләргә министрлык Рәхмәтен тапшырды. Мордва, рус милләт вәкил-ләре белән бергә, Дубенка районы Кочкурово урта мәктәбендә озак еллар тырышып балаларга татар теле һәм әдәбияты буенча белем, тәрбия бирvче Альфия Кетдус кызы Узбяковага Министрлык Рәхмәтен тапшырды.
Альфия Кетдусовна туган телен, әдәбиятын ихластан яратып киләчәк буынга ойрәтә. Ул югары категорияле белгеч, укучылары предмет олимпиадаларында призлы урыннар яулый, конкурсларда - беренчеләр. Анын һәрбер дәресе, тәрбияви чарасы уйланылып vткәрелә. Татар телен саклау остендә балалар һәм аларнын әти-әниләре, Ломат авылы якташлары белән кvп эшли.
Россия дәvләте кvпгасырлык тарихы, vз лингвистик мохите һәм vзенчәлекле мәдәнияте булган йозләгән халык очен туган йортка әverелгән. Шулай ук Мордовиябез дә.
«Дәvләтнен кvптеллелекне булдыру һәм ана ярдәм итv буенча максатчан адымнары,

законнар чыгарып жайга салуы, жәмәгатьчелекнен бу олкәдәге эшчәнлеге аеруча моһим...», - дип искәртеп vтте Мордовия халыклары Ассамблеясы рәисе Юрий Александрович Мишанин һәм шулай vз оешмасынын Рәхмәтләрен мукшы, әрзә матбугаты хезмәткәрләренә тапшырды.
Мордовия халкынын дуслык йорты директоры Раиса Ивановна Акашкина телнен тормышта тоткан урыны, дәрәжәсе турындагы сvләреннән сон, туган телне, милли традицияләрне саклау һәм vстерv очен тырыш хезмәт куючы торле милләт вәкилләре белән бергә, Мордовия татарларынын «Якташлар» милли-мәдәни автономия правлениясе рәисе Надия Низаметдин кызы Азисовага, «Юлдаш» дигән Мордовия татарларынын ижтимагый-сәяси газетасы корреспонденты Наилә Хәлил кызы Насыровага Рәхмәтен тапшырды.
Тантанада Рафаиль Зәки улы Аширов житәкчелегендә татар телен, мәдәниятын саклауда зур олеш керткән Мордовия милли-мәдәни автономиясенен ролен сәхнәдән ишеттерделәр. Тагы татар телен һәм әдәбиятын мәктәпләребездә ойрәнv турында, Мордовиянен Халык шагыйре исемен йорткән Камиль Абидулла улы Тангалычев житәкчелегендә Мордовия татарларынын «Юлдаш» дәvләт ижтимагый-сәяси газетасы унышлы эшләп килvе турында әйттеләр. Кичәне алып баручылар эфирда татар телендә «Туган тел» радиотапшыруы чыгуы, «Мәгариф» татар китапханәсе эшләве, vткән 2018нче елны Фагим Фатих улы Шафиев житәкчелендә Ислам мәдәни Үзәге ачылуы турында да сойләделәр. Мордовиябез горурлыгы булган олы татар әдәбияты классиклары Хади Такташ, Шәриф Камал, Абдрахман Абсалямовны искә алдылар. Ләмберәбездә ел саен «Сабантуй» милли-фольклор бәйрәмебез кин билгеләнеп vтvе турында да янгырады.
Мордовия татарларынын «Якташлар» милли-мәдәни автономия правлениясе рәисе Надия Низатетдин кызы Азисова чарадагы чыгышында болай диде: «Туган тел - тарихнын рухы, жаны ул. Туган тел – бала тугач та vзләштерелә башлаган олы хәзинә икәнлеге кон кебек ачык. Баланын ана телен vзләштерvе һәм аны актив куллануы, шул телдә тәрбия һәм белем алуы һәрьяклы vсеше очен унай шарт булып тора. Белгәнебезчә, кеше ни хәтле кvбрәк тел белсә, шул хәтле кvбрәк белем алырлык сәләткә ирешә. Мона тарихтан кvп мисаллар китерергә булыр дип уйларга урын бар». Тагы ул туган теленен һәр кеше гомерендә тоткан урыны,  Халыкара туган тел коненен нинди максатлар кvздә тотып килеп чыгышы, Мордовия татарларынын «Якташлар» милли-мәдәни автономиясе бу юнәлештә башкарган матур эшләре турында ишеттерде; боек шагыйребез Габдулла Тукайнын «Туган тел» шигырен яттан сәнгатьле сойләде. Ул: «Кадерле дуслар! Беркайчан да vз тамырларыгызны онытмагыз, чонки Туган телне соймичә, Туган илне яратып булмый. Кvпмилләтле республикабызда яшәvче һәркем очен бу кон һәрвакыт Тынычлык, Мәрхәмәтлелек һәм Татулык бәйрәме булсын!», - диде сvзен йомгаклап.
Чара мукшы, әрзә, рус, татар, украи-нлылар, әрмән, әзербәйжан, еврей, vзбәк һәм башка милләт халкынын шигырьләре, жырлары белән vрелеп барды; презентацияләрдән озекләр кvрсәтелде. Бәйрәмнен яме булып, «Мордовия Татар кызы-2018» республикабыз конкурсы жинvчесе Наилә Текарева башкаруында «Ник сонладын» жыры янгырады.

**Наилә Насырова**